**Яшим әле**

Бу дөньяда без кунакта гына,
Вакыт җиткәч китеп барабыз.
Табиблар да,түрәләр дә китә
Кемнәр китми? Әйтеп карагыз.

Гомерем буе тырышып эшләп,
Алтмышымны менә тутырам.
Үткәннәргә нәтиҗәләр ясап,
Иртә-кичләр уйлап утырам.

Тормыш мине төрле яктан
Сынады, тарсынып тормады.
Авыруын, авырлыгын бирде,
Тик аяктан ега алмады.

Күңелемне сагыш баскан чакта,
Туган нигеземә кайтамын.
Хәл-әхвәлен beләм исәннәрнең ,
Мәрхүмнәрнең барлыйм каберен.

Сагышларны тизрәк басар өчен,
Иртә таңнан китәм эшемә.
Башланмаган эшләр байтак икән,
Кирәк икән әле яшәргә.

Шул хыяллар белән җигелеп эшлим,
Ат елында бит мин туганмын!
Яшим әле, ут уйнатып яшим.
Сөендереп дусны-туганны.
Көендереп дошманны.

**Татарстан – туган ягым.**

Татарстан минем туган ягым
Синдә үтте яшьлек елларым.
Чит җирләрдән бәхет эзләмәдем,
Синдә таптым бәхет юлларын.

Авылымның изге чишмәләре
Саф суларын бүләк иттеләр.
Якташларым минем , дус-ишләрем
Һәр вакытта якын күрделәр.

Мин бәхетле туган халкым белән,

Горурланып яшим дөньяда.
Авырлыклар безне һич куркытмый
Сез дусларым янда булганда.

Тату яши бездә бар халык та,
Татар иле якын барсына.
Ыгы-зыгы килеп торган җирләр
Менә бездән үрнәк алсыннар.

Җитәкчебез тимер кеше
Җиңел түгел аның эше!
Бу болгавыр заманда,
Татарстан алга бара.

Быел безнең Үгез елы,
Бирсен Ходай илгә муллык.
Тырышып эшлик үгез кебек,
Шул вакытта булыр байлык.

**Баллы чишмә.**

Очраштырды безне язмыш,
Баллы чишмә буенда.
Су эчәргә килгән идең
Җәйге сабан туенда.
    Эх, дускаем, кил әле,
    Баллы чишмә буена.
    Таллар да сине сагына.
    Син генә гел уемда.
Урамнардан җырлап үттем.
Авылым йоклап ятканда.
Саубуллаштык синең белән,
Сызылып таңнар атканда.
      Кушымта
Сагынып кайтам авылыма,
Төштем чишмә буена.
Таллар белән сөйләшәмен,
Ә син һаман уемда.
    Ага чишмә сулары,
    Тал тамырлары аша.
    Сагынуларымны җиткерәм
    Шушы җырларым аша.
    Сиңа шул җырым аша.

**Ялгыз каен.(җыр)**
Яр читендә, су буенда,
Үсә ялгыз бер каен.
Шул каенны сагынып кайтам
Син искә төшкән саен.

Төшләремә керәсең дә
Телгәлисең үзәкне.
Туктатасың инде ахры
Яраланган йөрәкне.

Яр читендә, су өстендә,
Йөзә парлы аккошлар.
Нигә безнең өчен генә
Авыр булды язмышлар.

**Уйлану.**
Су буенда, чирәмлектә,
Ялгыз уйлап утырам.
Үтә гомер, картаябыз,
Илле бишне тутырам.

Күз алдына китерәмен
Бала-чага елларын.
Еракларга даны таралган
Бәзәкә болыннарын.

Ничек инде онытасың,
Печән чапкан чакларны.
Сызылып таңнар аткан чакта
Кешнәп чапкан атларны.

Бата-чума сазлыгында
Әз чапмадык күрәнен.
Сазлык диеп тә тормадык
Шунда салдык кибәнен.

Әлсерәп тамак кипкән чакта
Суны эчтек сазлыктан.
Күрше күлгә дә бармадык
Вакытыбыз азлыктан.

Хәзер инде бүтән вакыт,
Печән үсә кырларда.
Чалгы белән дә чапмыйлар,

Ишетелми җырлар да.

Үзгәртеп корабыз диеп
Болгаттылар заманны!
Үзгәрделәр кешеләр дә,
Белми дусны-туганны.

Җитте вакыт уйланырга,
Кеше гомере бик кыска.
Ярдәмләшик яшик, дуслар,
Үтмәсен гомер бушка.

## Кайтам әле туган авылга

Кайтыйм әле туган якларыма,
Эчим әле чишмә суларын.
Сызгырып бер үтим әле
Бәбкә куган инеш юлларын.

Инеш буендагы тал-тирәкләр,
Кая сезнең сылу чагыгыз?
Кая безнең матур Пинәрәдә
Балык тотып йөргән чагыбыз?

Туган якның матур болыннарын
Җырлап үтәсем килә.
Яңа кипкән печән өсләрендә
Яллар итәсем килә.

Булмас инде беркайчан да,
Хыялларым шулай калырлар.
Болыннарым, чабар печәннәрем
Су астында инде калдылар.

Ә шулай да, кайтам әле
Туган якка,туган авылга.
Туган туфрак мине тарта
Мәңгелеккә шунда калырга.

Зөфәр Гыймадиев